| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2019 ел №17

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты резерв фонды акчаларын тоту Тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.(1нче кушымта)

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ (Р.Х. Хәмидуллин) Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Резерв фондыннан чыгымнарны расланган Нигезләмә нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Резерв фонды акчаларын файдалануны тикшереп тору Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.Әлеге карарны Зеленая Роща авыл җирлегендә урнашкан урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, шулай ук Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми ( pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштырырга

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Потапов

1 нче номерлы кушымта
« Зеленая Роща авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты карарына
2019 елның 6 декабре. № 17

**КАГЫЙДӘЛӘР**
Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының резерв фондын (алга таба - резерв фонды) Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы авыл җирлегенең кетелмәгән чыгымнарын финанслауга тоту тәртибен (алга таба - җирлек) билгели.

1.2. Резерв фонды акчалары тиешле финанс елына җирлек бюджетында каралмаган көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмияттәге чараларны финанслау өчен, шул исәптән табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү буенча авария-торгызу эшләрен, агымдагы финанс елында урын алган башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен каралган.

1.3. Әлеге Нигезләмәне куллану максатларында агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы җирлеге бюджетында каралмаган һәм киләсе финанс елына бюджет расланганчы кичектерелергә мөмкин булмаган чыгымнар көтелмәгән чыгымнар дип таныла.

## 2. Резерв фондын формалаштыру тәртибе

2.1. Резерв фонды җирлек бюджеты чыгымнары составында төзелә.

2.2. Резерв фонды күләме Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « _ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары белән чираттагы финанс елына җирлек бюджетын раслаганда билгеләнә һәм җирлек бюджеты чыгымнарының расланган гомуми күләменең 3% тан артмаска тиеш.

## 3. Резерв фонды акчаларын тоту юнәлеше

3.1. Резерв фонды акчалары көтелмәгән чыгымнарны финанслауга, шул исәптән:

ремонт, коткару, авария-торгызу эшләрен башкаруга һәм җирлектә стихияле бәла-казаларның һәм башка гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка чараларны үткәрүгә көтелмәгән чыгымнар;

иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә ярдәм итү;

республика һәм җирле әһәмияттәге чараларны үткәрү;

бүләкләр, юбилей медальләре, грамоталар әзерләү;

җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча очрашулар, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм семинарлар үткәрү;

социаль һәм җитештерү елкәсендәге казанышлары өчен гражданнарга бер тапкыр бирелә торган премияләр һәм матди ярдәм күрсәтү;

кичектергесез ремонт һәм торгызу эшләрен үткәрү;

социаль-мәдәни, физик культура һәм спорт үсешенә ярдәм итү;

җирле үзидарә органнарының уртак бурычларын хәл итүгә, матди-техник шартлар булдыруга ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар;

җирле үзидарә органнары карарлары буенча үткәрелә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча көтелмәгән башка чаралар һәм чыгымнар.

## 4. Резерв фондыннан акча бүлеп бирү тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « ____ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Резерв фондыннан акча Башкарма комитет җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә бүлеп бирелә.

4.2. Башкарма комитет җитәкчесенең резерв фондыннан акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсе җирле үзидарә органнары һәм җирлекнең бу чараларны гамәлгә ашыручы учреждениеләре карамагында булган акчалар җитәрлек булмаган очракларда кабул ителә.

4.3. Җирлек муниципаль берәмлеге учреждениеләре, оешмалары һәм предприятиеләре башкарма комитет җитәкчесенә документлар, смета-финанс хисаплары, шулай ук кирәк булган очракта-комиссия, экспертлар бәяләмәсен сорап, язмача мөрәҗәгать юллыйлар.

4.4. Эшчәнлеге резерв фондыннан акча бүлеп бирелә торган башкарма комитет исәп-хисапларны тикшерә һәм Башкарма комитет җитәкчесе өчен бүлеп бирелә торган акчалар күләме, аларны тоту максатлары турында бәяләмә әзерли.

4.5. Башкарма комитетның резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсе проектлары Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУсын тиешле йөкләмәне авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең алганнан соң 3 көн эчендә әзерли.

4.6. Җирлек Башкарма комитеты җитәкчесенең резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турындагы күрсәтмәсендә ассигнованиеләрнең гомуми күләме һәм аларны тотуның юнәлеше, аларны алучыларга һәм уздырыла торган чараларга бүлеп күрсәтелә. Җирлек башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсендә каралмаган максатларда акчалардан файдалану рөхсәт ителми.

4.7. Резерв фондның акчаларын финанслау Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан җирлек башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Резерв фонды акчаларын тоту турында хисап

5.1. Җирлекнең башкарма комитеты, резерв фондка акча бүлеп бирелә торган учреждениеләр, оешмалар һәм предприятиеләр акчаларны максатчан файдаланган өчен җаваплы булалар һәм тиешле чаралар уздырганнан соң бер ай эчендә Лениногорск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» на бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышы турында хисап бирәләр.

5.2. Резерв фонды бюджет акчаларын алучының максатсыз файдалануы аларны бәхәссез тәртиптә тартып алуга китерә.